ГЛАВА ИЛЯКСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**20 март 2024 ел** **№2**

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Игәнә-Баш авылы гражданнары халык җыенының “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” һәм “2024 елда Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында” мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Игәнә-Баш авылы гражданнарының халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. “2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Игәнә-Баш авылы гражданнарының халык җыенының “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” һәм “2024 елда Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында” мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Игәнә-Баш авылы гражданнары халык җыенын Игәнә-Баш авылы мед.пукт бинасында, Игәнә-Баш авылы Совет урамы 16а йорт адресы буенча, 2024 елның 30 мартына 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Игәнә-Баш авылы гражданнарының халык җыенының “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” һәм “2024 елда Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

«1. Урамнарның яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Игәнә-Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар һәм материаллар сатып алу; агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту));

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Игәнә-Баш торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Игәнә-Баш торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу(килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу)?

"ӘЙЕ" "ЮК"?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Илексаз авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Игәнә-Баш авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Илексаз авыл җирлеге башлыгы: Ф.М.Гыйлфанов